**Д.Х.Хөснетдинов**

**Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан**

# ҖЫРЛАРДА ТӨСЛӘР ПОЭТИКАСЫ

## (Лирик җырлар мисалында)

(Тикшеренүләр *11-14-1602а/В* (РГНФ) номерлы грант кысаларында башкарылды)

Татар халык җырларының бер төркемен лирик җырлар тәшкил итә. Аларның асылында һәркем күңеленә дә хуш килгән, һәр кешегә дә якын булган эчке кичерешләр, уйланулар, хис-тойгылар ята. Шуңа күрәдер, лирик җырларның таралу һәм яшәү даирәсе иксез-чиксез. Алар эш вакытында да, ял иткәндә дә, юлда барганда да җырлана.

Бу жанрга кергән традицион җырларның лирик геройлары - игенчеләр, батраклар, читтә мал, бәхет эзләп йөрүче сәфәрчеләр, хатын-кызлар. Лирик җырларны тагы да аерыбрак, туган ил, туган як турындагы, хатын-кыз язмышы, мәхәббәт турындагы һәм шаян лирик җырларга таркатып карыйлар.

Җырларның мәгънәви тирәнлеген, шигъри гүзәллеген шул геройларның төрле төсләрдә гәүдәләнгән хис-кичерешләре билгели. Шушы нисбәттән, лирик җырларда кулланылган төсләр, төсле сурәтләр аша да чагылыш таба.

Лирик җырларда иң еш чагылыш тапкан төс – ак. Чисталык, сафлык, тынычлык, изгелек, гүзәллек символы саналган ак төс лирик җырларның романтик юнәлешен ассызыклый. Әйтик, *ак чәчәк* компоненты шуңа мисал булып тора.

Алмагачын вак диләр,
Чәчәкләрен ак диләр, дусларым;
Кая барсаң, кайда йөрсәң,
Сез дусларны мактыйлар.

Ак төс аша чагылдырылган табигый матурлык, сафлык лирик җырларда телгә алынган ак төстәге кием һәм атрибутлар аша да

тасвирлана. Гомумән, татар җырларында ак төстәге кием кигән һәм атрибутларга ия булган герой рухи матурлык, изге күңеллелекнең романтик гәүдәленеше булып тора. Мәсәлән, *ак калфак*.

*Ак калфагың* кисәнә,
Кыңгыр салып йөрсәнә;
Ят илләрдән яучы килсә,
Сөйгәнем бар дисәнә.

Киң танылган “Ак калфак” җырында да шушы ук күренешкә тап булабыз.

Ай, әле бик еракта идек без,
Илле чакрым җирне килдек без;
*Ак калфакның* табылган чагы,
Туганнарның сагынган чагы.

Ак калфак татар хатын-кызларына хас булган эчке матурлык, тыйнаклыкның гомумкулланылыш алган символы булып яңгырый.

Безнең дә сөйгәннәр, шулар була:
*Ак калфагы* башында,
Чәй ясыйдыр каршымда.

Ак калфактан кала, лирик җырларда *ак күлмәк* (аклы ситсы күлмәк), *ак пирчәткә, ак яулык, ак бүрек, ак каптырма, ак сөлге* кебек кием-салым, аксессуарлар урын ала.

Ак күлмәк, аклы ситсы күлмәк мәхәббәт турындагы лирик җырларда еш чагыла. Ул сөйгән ярның сөйгәненә тугърылыклы булуы, саф хисләренә тап төшермичә саклавын, намуслылыкны аңлату өчен кулланыла булса кирәк.

*Аклы күлмәгем* каралса,
Каралысын киярмен;
Яшерен янып, яшерен көеп,
Бәгырем, сине сөярмен.

Югарыда санап кителгән барлык компонентлар да сафлык, гыйффәтлелек, эчкерсез самимилек, рухи матурлыкның төсле сурәте буларак файдаланыла. Ак төс шулай ук тышкы матурлыкның характерлы күрсәткече буларак та яңгырый:

Ука буе бик ямьле,
Ука суы бик тәмле:
Ука суын эчкән кызлар
Нечкә билле, *ак тәнле*.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: ак төснең уңганлык, тырышлык белән дә ассоциатив уртаклыгы бар, чөнки шушы сыйфатларга ия булганнар гына кер кунмаган, ап-ак чиста киемнәрдән йөри. Димәк, ак төстәге киемнәр иң туры гади мәгънәсендәге чисталык билгесе буларак та җырларда кулланыла, ак төстәге кием йөртүчегә тырыш, булдыклы дип соклану урын ала.

Лирик җырларда ак төстәге кош-җәнлекләр шактый еш искә алына. Мәсәлән, *ак үрдәкләр* (“Дусларым, үз ишләрем”), *ак куян* (“Хафизәләм, иркәм”), *ак сусарлар* (“Картуф”). Барлык очракта да ак җәнлекләр, ак кошлар шатлыклы, куанычлы хәбәрләрнең алхәбәре ролен үтиләр.

*Ак сусарлар* хәбәр бирә
Судагы кондызларга...

Кара төс кулланылышына килгәндә, тарихи җырлардан аермалы буларак, ул бары тик уңай ассоциатив мәгънәне йөртә, төгәлрәге, тышкы матурлыкның характерлы күрсәткече буларак бигеләп үтелә. Мәсәлән, лирик халык җырларында *кара чәч, кара кашлы, кара керфекле һәм кара күзле* хатын-кыз иң чибәр зат булып санала, аның матурлыгына дан җырлана:

*Чәчләрең кара ефәк* күк,
Ефәк бирим үрергә;
Бик сагынгач, бик саргайгач, Нурия,

Килдем сине күрергә.

Лирик җырларда, гомумән, кулланылыш ешлыгы буенча уңай күзаллау, ассоциацияләр уята торган төсләр, ягъни актан тыш, ал һәм зәңгәр өстенлек ала.

Ал төс – мәхәббәт, саф сөю хисләре, романтика, хыялыйлык төсе буларак кабул ителгән, шуңа күрә мәхәббәт турындагы лирик халык җырларында *ал таң, ал кораб, ал чәчәк,* шулай ук аерым алынган ал-гөл компоненты урын ала.

*Ал таң* белән, кошлар белән,<br>Йокысыннан уяна;<br>Ярышып эшләгән чагында<br>Алгы сафларда бара.

*Ал яулык, ал тасма, ал алъяпкыч* кебек сүзтезмәләр исә, сөйгән яр турында җырланган җырларда аерылмас атрибут буларак файдаланыла. Татар халкында ак төсеннән кала, ал романтик бизәлеш өчен куллана торган икенче урында торучы төсле сурәт.

Агыйделкәйләрнең буенда<br>*Ал яулыгым* калды. Ал, җаный;<br>Мине дә ташлап, ятны сөйсәң,<br>Оҗмахлардан мәхрүм кал, җаный.

Ал-гөл, аллы-гөлле компонентына килгәндә, әлеге сүзтезмә искиткеч матур, төрле төстә яисә бик яхшы күчерелмә мәгънәләрен белдерә. Ягъни *ал һәм гөл төс* һәм үсемлек мәгънәләреннән узып, гүзәллек, матурлык символы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә.

*Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем*,<br>Рәхәт үтсен җәйләрең!

Ал төс белән охшаш рәвештә, лирик җырларга *зәңгәр шәл, зәңгәр яулык, зәңгәр күлмәк* төсле образларын куллану хас.

Зәңгәр күбәләктәй була

*Зәңгәр күлмәге*н кисә.

Нәфисәнең маңгай чәчен

Әлеге мисалда зәңгәр төс романтика, яшьлек, тыйнак матурлык чагылышы сурәте вазифасын үтиләр. Шунысы билгеләп үтү зарур: тышкы матурлык күрсәткече итеп, кара төсне билгеләп узсак та (*кара күз, кара каш, кара чәч*), *зәңгәр күзлә*р сүзтезмә мисалында, зәңгәр төснең дә еш таралыш алган матурлык идеалының бер күрсәткече икәнен аңлыйбыз.

Синең *зәңгәр күзлә*реңне

Күзләр өчен килдем мин;

Күзләреңнән яшерен серләр

Эзләр өчен килдем мин.

Лирик җырларның туган як, туган җир турындагы төркемчәсендә *яшел* төс кулланыла. Яшел үлән, яшел болын сүзтезмәләре составында туган җирнең матурлыгын, күңелгә якынлыгын, читтә җирләргә сәфәр кылучылар өчен туган илдәге тыныч тормышны белдерүче чарасы итеп файдаланыла дисәк, дөрес булыр.

“Ишек алдым *яшел үлән*,

Иртә торып, әй, ат җибәр,

Атна арасы алты да көн,

Уртасында, әй, хат җибәр”.

Лирик җырларда яшел төстән кала сары һәм кызыл төсләрне билгеләп үтәргә кирәк.

*Кызыл төс* биредә югарыда әйтеп кителгән тышкы матурлык күрсәткеченең состав компоненты ролен үти:

Без кызларны яратабыз

*Бите кызылга* күрә..

Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч,

Бөрлегәннән *кызыл йөзләрең*...

Мисалдан чыгып, фикер йөртсәк, кызыл йөз сәламәтлек билгесе һәм шулай ук ялкынлы көчле характер, янып торучы темперамент чагылышы кебек тә каралырга мөмкин. Нәтиҗәдә, лирик җырларда кызыл төс – көч-куәт, темпераментның ассоциатив мәгънәсен йөртүче төс сыйфатында ачыла.

*Сары төс* тарихи җырлардагы кебек үк ассоциатив мәгънәләрен ача һәм шул ук сагыш, юксыну символы булган *сары чәчәк, сары күлмәк* кебек сурәтләр урын ала.

*Сары чәчәк* ата көнбагыш,
Кайчан туар безгә куаныч?

Әлбәттә, татар халкының яраткан образы сандугач, сары сыйфатламасы белән берлектә, лирик җырларда да кулланыла:

“Таң алдыннан *сары ла сандугач*
Сандугач тавышы моңлы икән,
Сөйгәнеңне өзелеп сагынгач.”

Лирик җырлар арасында бары ике мисалда гына булса да, тарихи җырларда кулланылган *җирән төс  җирән ат, җирән кашка* образы калкып чыга:

*Җирән аткай* су буенда...
Миңа дигән шул матур кыз
Кайчан керер куеныма?”

Гомуми нәтиҗә ясап әйткәндә, лирик татар халык җырларында *ак, кара, ал (ал-гөл), зәңгәр, яшел, кызыл, сары* һәм *җирән төсләр* чагылыш таба. Шулар арасында бары сары төс кенә тискәре ассоциатив мәгънәләрне ача, сагыш, моң, юксыну, югалту билгесе булып карала. Ак, кара, ал, зәңгәр, яшел, кызыл, җирән төсләр исә, тарихи җырлардагы кулланылышыннан аермалы буларак, бары тик уңай ассоциатив мәгънәләрне йөртәләр, тышкы һәм эчке матурлык, романтик мөнәсәбәтләр, хыялыйлык, яшьлек төшенчәләрен ачалар.

Чыганаклар

1. Әхмәдуллин А. Әдәбият белеме сүзлеге / А.Әхмәдуллин. – Казан: Татар кит. нәшр., 1990. – 238 б.

2. Миңнуллин К. Җырларның шигъри табигате / К.Миңнуллин. - Казан: Мастер Лайн, 1999. – 107 б.

3. Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар / Төз. И. Надиров – Казан: Татар кит. нәшр., 1988. – 485 б.